Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

ХӘБӘР ИТҮ

Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Мөрәле авыл җирлеге, Мөрәле авылы, Яшьләр ур., 2 ж/к адресы буенча урнашкан, 16:21:160101:360 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1. Җир кишәрлеге буенча гавами кадастр картасыннан мәгълүмат;
2. Мөрәле авыл җирлегенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
3. Мөрәле авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләреннән өземтә.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

1. Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләнең асылы буенча чыгышлар.
2. Гавами тыңлауларда катнашучыларның сорауларын һәм тәкъдимнәрен карау.

Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга барлык чыгышлар тәмамланганнан соң сораулар бирергә хокуклы. Сораулар һәм тәкъдимнәр язма рәвештә бирелә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы 2024 елның 06 сентябреннән 2024 елның 16 сентябренә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты, җир кишәрлеге урнашкан территориаль зона чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шушы территориаль зона чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, җир кишәрлеге чикләрендә даими яшәүче гражданнар, шундый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы: Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк ур., 63 йорт, адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы, 2024 елның 06 сентябре.

Экспозицияләргә (экспозицияләргә) бару мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: 2024 елның 06 сентябре - 2024 елның 16 сентябренә кадәр 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне иҗтимагый фикер алышуларда (гавами тыңлауларда) катнашучыларның кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше: җир кишәрлегенә карата җир кишәрлегеннән файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегендә 2024 елнын 06 сентябреннән 2024 елның 16 сентябренә кадәр язма рәвештә кабул ителә.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 2024 елның 16 сентябрендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк ур., 63 й. адресы буенча авыл мәдәният йорты.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылган рәсми сайт турында мәгълүмат: Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтының «Башкарма комитет карарлары» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru).

Әлеге хәбәрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Сайтка керүчеләр өчен файдалы мәгълүмат» бүлегендә (http://kaybici.tatarstan.ru) һәм Кайбыч районы, Мөрәле авылы, Үзәк ур., 63 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты мәгълүмат стендында бастырырга.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе — А.Н. Макаров